## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“6” ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, 2020 елның 30 октябрендә 19 сәгать 00 минутта, 2020 елның 4 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2020 елның 6 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, чүп-чар материалларны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, транспорт хезмәте күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

- Культурная урамындагы басманы ремонтлау өчен материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- авыл территориясен яшелләндерү (Чишмәле ур.);

- үлән чабу өчен ваклаучы чапкыч сатып алу;

- Түбән Бәрәскә авыл җирлеге территориясенә кергәндә аншлаг (композиция) урнаштыру;

- юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны, үсентеләрне кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3) Паркны төзекләндерү:

- парк территориясен чистарту, транспорт хезмәте, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- күлне төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенының беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 638 (алты йөз утыз сигез) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 398 (өч йөз туксаз сигез) кеше, бу 62,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 398 (өч йөз туксан сигез) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2021 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, чүп-чар материалларны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, транспорт хезмәте күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

- Культурная урамындагы басманы ремонтлау өчен материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- авыл территориясен яшелләндерү (Чишмәле ур.);

- үлән чабу өчен ваклаучы чапкыч сатып алу;

- Түбән Бәрәскә авыл җирлеге территориясенә кергәндә аншлаг (композиция) урнаштыру;

- юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны, үсентеләрне кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3) Паркны төзекләндерү:

- парк территориясен чистарту, транспорт хезмәте, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- күлне төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)” мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.